**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
10 февраля 2022 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 2 ноября 2012 года № 73-ЗРТ «Об оказании бесплатной юридической помощи гражданам в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 11 (I часть); 2013, № 11 (I часть); 2014, № 1 – 2, № 12 (II часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 44 (часть I); 2018, № 1 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 3 статьи 7 дополнить словами «, в том числе решение вопросов об учреждении и обеспечении деятельности государственного юридического бюро»;

2) часть 1 статьи 9 дополнить пунктом 3 следующего содержания:
«3) государственное юридическое бюро.»;

3) дополнить статьей $10^1$ следующего содержания:
«Статья $10^1$. **Оказание бесплатной юридической помощи государственным юридическим бюро**

1. В целях оказания гражданам бесплатной юридической помощи решением Кабинета Министров Республики Татарстан может быть создано государственное юридическое бюро.
2. Государственное юридическое бюро создается в форме государственного казенного учреждения Республики Татарстан.
3. Государственное юридическое бюро оказывает все предусмотренные статьей 4 настоящего Закона виды бесплатной юридической помощи.»;

4) в статье 12:

а) в абзаце первом части 2 слово «Адвокаты» заменить словами «Государственное юридическое бюро и адвокаты»;

б) в абзаце первом части 3 слово «Адвокаты» заменить словами «Государственное юридическое бюро и адвокаты»;

5) в статье 14:

а) в части 3 слова «в государственные органы» заменить словами «в государственное юридическое бюро»;

б) в части 4 слова «Уполномоченные государственные органы» заменить словами «Государственное юридическое бюро»;

6) часть 1 статьи 17 после слов «государственных внебюджетных фондов,» дополнить словами «государственное юридическое бюро,»;

7) часть 2 статьи 18 после слов «связанных с» дополнить словами «созданием и деятельностью государственного юридического бюро и».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
25 февраля 2022 года
№ 7-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 10 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяның 3 пунктында «, шул исәптән дәүләт юридик бюросын гамәлгә кую һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү турындагы мәсьәләләрне хәл итү» сүзләрен өстәргә;

2) 9 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3) дәүләт юридик бюросы.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ статья өстәргә:
«$10^1$ статья. **Дәүләт юридик бюросы тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү**

1. Гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән дәүләт юридик бюросы төзелергә мөмкин.
2. Дәүләт юридик бюросы Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе рәвешендә төзелә.
3. Дәүләт юридик бюросы әлеге Законның 4 статьясында каралган түләүсез юридик ярдәмнең барлык төрләрен дә күрсәтә.»;

4) 12 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче абзацында «адвокатлар» сүзен «дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешнең беренче абзацында «адвокатлар» сүзен «дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар» сүзләренә алмаштырырга;

5) 14 статьяда:

а) 3 өлештә «дәүләт органнарына» сүзләрен «дәүләт юридик бюросына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Вәкаләтле дәүләт органнары һәм дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы адвокатлар» сүзләрен «Дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучы дәүләт юридик бюросы һәм адвокатлар» сүзләренә алмаштырырга;

6) 17 статьяның 1 өлешендә «бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары,» сүзләреннән соң «дәүләт юридик бюросы,» сүзләрен өстәргә;

7) 18 статьяның 2 өлешендә «түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче» сүзләреннән соң «дәүләт юридик бюросын төзүгә һәм аның эшчәнлегенә һәм» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 25 февраль
№ 7-ТРЗ